СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**10. 01.2017 ел** **№ 31**

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«Арча муниципаль районының «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2015 елның 31 мартындагы 57 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт турында (2016 елның 19 мартындагы 13 номерлы карары редакциясендә) Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Арча районы прокурорының 2016 елның 30 июнендәге 224-ФЗ номерлы һәм "Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә:

1. Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2015 елның 31 мартындагы 57 номерлы карары (2016 елның 19 мартындагы 13 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Арча муниципаль районының «Иске Чүриле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 7.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына, вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә, шулай ук яллаучы (эш бирүче) вәкиленең тиешле карары булганда - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә туры килү таләп ителә.»;

**б) 7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«7.2.Һөнәри белем бирү дәрәҗәсенә, муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен кирәкле белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясындагы 3 өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен типик квалификация таләпләре нигезендә билгеләнә. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләре, муниципаль хезмәткәрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи инструкциясе белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясендә шулай ук белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу; вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә ике ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы.»;

3) өлкән һәм кече төркемнәрнең муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

4) муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук тиешле вазыйфаи төркемнәрнең дәүләт граждан хезмәте Вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт Вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәте Вазыйфаларында эш стажы да исәпкә алына.

5) муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә тиешле вазыйфаи төркемнәр һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәтенең башка төр вазыйфаларында шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында эш стажы исәпкә алына.

6) муниципаль районнып дирле хакимияте башлыгы вазыйфасына контракт буенча билгелене торган кандидатларга остеме талеплер белен идаре иту эшченлеге кименде биш ел булу билгелене. Идарә эшчәнлеге астында әлеге өлештә оешма җитәкчесе, җитәкче урынбасары, дәүләт органы, Муниципаль орган, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында эшләү аңлана. Җирле администрация башлыгы вазыйфасына контракт буенча билгеләнә торган кандидатларга өстәмә таләпләр шулай ук муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнергә мөмкин.»;

**в) 9.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:**

«12) ел саен керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда, шулай ук һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат бирергә, шулай ук һәр алыш-биреш буенча җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар тапшырырга - әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә һәм әлеге алыш-бирешләр кылган акчалар алу чыганаклары турында.»

**г) 10.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пунктча өстәргә:**

«11) муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18.1 статьясында каралган белешмәләрне тапшырмау;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина